Татарстан республикасы Мөслим муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
Тат.Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе

КАРАЛДЫ
Методик берләшмә житәкчесе:
_________ Вилданова Л.Р.
Беркетмә №1,
"29" нчы август, 2019 нчы ел.

КИЛЕШЕНДЕ
Уку-укыту эшләре буенча директор
урынбасары: ___________ Шаймухаметова Р.И.
"29" нчы август, 2019 нчы ел.

РАСЛЫЙМ.
Мәктәп директоры
_________ В.М.Шаева.
Боерык №__,
"__" ______ 2019 нчы ел.

# "ТУГАН ТЕЛ (ӘДӘБИ УКУ)"ННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

| | |
|---|---|
| Белем бирү баскычы | Башлангыч белеем бирү |
| Сыйныф | 1-4 |
| Эш программасын үзләштерү аралыгы | 2019- 23 |
| Үзләштерү дәрәжәсе (база, профиль) | база |
| Төзүчеләр | Вилданова Ләйсән Рәсим кызы, I квалификацион категорияле укытучы<br>Нурлыгаянова Фирсинә Өлфәт кызы, , I квалификацион категорияле укытучы<br>Петрова Гөләндәм Кашиф кызы, I квалификацион категорияле укытучы |

Педагогик киңәшмә утырышында кабул ителде.

Беркетмә №1, " 29" нчы август. 2019 ел.

1-4 сыйныфлар өчен әдәби уку фәненнән көтелгән предметнәтиҗәләре.

Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә «Әдәби уку» предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар әдәбиятының күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм әһәмияте турында күзаллау формалаштырыла.

Башлангыч мәктәпне тәмамлаганда укучыда алга таба белем алуга кирәкле нигез салына. Әйләнә-тирә дөньяны танып белүдә әдәби укуның ролен һәм кирәклеген, кешенең интеллектуаль культурасын формалаштырудагы әһәмияте аңлатыла. Укучыларда үз-үзеңне һәм әйләнә-тирә дөньяны танып белү өчен системалы рәвештә белем алуга ихтыяҗ тудырыла. Кече яшьтәге мәктәп баласы, тормышта үз урынын табу, танып белү эшчәнлеген киңәйтү максатыннан, әдәби әсәрләрне кызыксынып өйрәнәчәк дип көтелә.

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында әдәби укуга өйрәтүнең **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

– укучыны әдәби әсәрләр аша Туган иле, туган ягы, дөнья халыклары мәдәнияте һәм тарихы белəнтаныштыру;
– әдәби әсәрне, сәнгатьнең үзенчәлекле бер төре буларак, башка сәнгать әсәрләре белән чагыштырыпөйрәнү;
– әсәрнең жанрын билгеләгәндә, геройларга характеристика биргәндә анализ, чагыштыру, каршы кую ысулларынкуллану;
– төрле характердагы әсәрләр белəнтаныштыру;
– кече яшьтәге мәктәп баласын үз фикерен курыкмыйча әйтергә, башкалар фикерен тыңлый һәм хөрмәт итәргәкүнектерү;
– укучыларны әдәби, фәнни, фәнни-популяр текстлардан үзләренә кирәкле мәгълүматларны эзләп таба белергәөйрәтү;
– сүзлек, энциклопедияләр белән эшләү күнекмәләребулдыру;
– төрле ситуацияләрдә, сөйләм этикеты кагыйдәләрен үтәп, диалог, монолог төзергәөйрәтү.

## 1. 1-4 нче сыйныфлар өчен эш программасының эчтәлеге.Сөйләм һәм уку хезмәте төрләренәталәпләр

***Тыңлау (аудирование)***

Ишеткән сөйләүне кабул итү (әңгәмәдәшеңнең фикерләрен, төрле текстларны укыганда тыңлый белү). Сөйләм барышында әйтелгән фикерне аңлау, ишеткән әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләү, сөйләмдә куелган максатны аңлый алу, дөрес, фәнни яктан танып-белү, әдәби әсәрләрне тыңлаганнан соң сораулар куя белү таләп ителә.

***Уку. Кычкырып уку***

Иҗекләп укудан әкренләп йөгерек, аңлап, сүзләп укуга күчү.

Уку тизлеген даими рәвештә арттыра бару. Аны текстның мәгънәсен тулы күләмдә аңларлык дәрәҗәгә җиткерү. Укыганда орфоэпик һәм интонацион нормаларны саклау. Җөмләләрне укыганда тыныш билгеләрен интонация белән аера белү. Төрле төрдәге һәм типтагы текстларның мәгънә үзенчәлекләрен аңлау, аларны интонация ярдәмендә бирү.

***Эчтән уку***

Яшь үзенчәлекләренә туры килгән күләмдәге һәм жанрдагы әсәрләрне эчтән укыганда мәгънәсен аңлап җиткерү. Уку төрләрен билгели белү (өйрәнү, танышу, карап чыгу, сайлап уку). Тексттан тиешле мәгълүматны таба белү. Фактлар, тасвирлау, өстәмә фикерләр белән тулыландырып уку.

***Төрле стильдәге текстлар белән эш***

Төрле стильдәге – әдәби, дәреслек, фәнни-популяр текстлар турында гомуми күзаллау булдыру, аларны чагыштыра белү. Бу төр текстларның максатларын билгеләү. Фольклор текстының үзенчәлекләрен табу. Текстны төрле җөмләләр тезмәсеннән гамәли аеру. Әсәрнең исеменә һәм бизәлешенә карап, эчтәлеге турында белә алу.

Текстның темасын, төп фикерен, төзелешен ачыклау; текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, аларны исемләү. Төрле мәгълүмат белән эшли алу. Текст буенча сорауларга җавап бирү, тема буенча чыгыш ясау, иптәшеңнең чыгышын тыңлау, әңгәмә вакытында, текстны кулланып, җавапларны тулыландыруда катнашу. Төрле белешмә һәм иллюстратив-сәнгать материалларыннан файдалану.

***Библиографик культура***

Сәнгатьнең бер төре буларак китап. Китап – кирәкле белемнәрнең чишмәсе. Россиядә һәм татарларда беренче китаплар, аларның басыла башлау тарихы турында гомуми күзаллау. Уку китабы, әдәби әсәр, белешмәлекләр. Китап элементлары: эчтәлеге яки бүлекләр исемлеге, титул бите, аннотация, иллюстрацияләр. Китапта бирелгән мәгълүмат төрен ачыклау: фәнни, әдәби (тышкы билгеләренә һәм анда бирелгән белешмә-иллюстратив материал). Китап типларын ачыклау: әсәр, җыентык, сайланма әсәр, вакытлы матбугат, белешмәлекләр (сүзлек, энциклопедия).

Бирелгән исемлек, картотека буенча китап сайлый белү. Алфавит каталогыннан файдалану. Яшь үзенчәлекләренә туры килгән сүзлек һәм белешмә материалларны мөстәкыйль рәвештә куллана белү.

***Әдәби әсәр тексты белән эш***

Әсәрнең исемен аның эчтәлегенә мөнәсәбәтле рәвештә аңлау. Укытучы ярдәмендә әдәби әсәрнең сәнгати үзенчәлекләрен билгеләү. Халык авыз иҗаты әсәрләренең гомумкешелек әхлак кагыйдәләрен һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен күрсәтүен ачыклау. Әсәр геройларының эш-гамәлләренә әхлак кагыйдәләре нормаларыннан чыгып бәя бирү. Туган ил, Ватан төшенчәсен аңлау, Россия халыклары мисалында әдәбиятта төрле милләт халыкларының туган илгә мәхәббәте турында күзаллау булдыру. Төрле халыкларның фольклорында тема, идея, геройларның охшашлыгы. Телнең сурәтләү чараларын кулланып, мөстәкыйль рәвештә текстны күз алдына китерү: укытучы сораулары буенча, әсәрнең лексик үзенчәлекләрен истә тотып, эпизодларны бер-бер артлы искә төшерү, иллюстрацияләр буенча сөйләү, эчтәлеген сөйләү.

Сәнгатьлелек тудыру чараларын кулланып, бирелгән тексттагы геройга характеристика бирү. Әсәрдән геройны һәм вакыйгаларны характерлаган сүзләрне табу. Укытучы ярдәмендә катнашучыларның эш-гамәлләренең мотивларын билгеләү, аларны анализлау, чагыштыру. Геройларның эш-гамәлләрен капма-каршылыгы яки охшашлыгы буенча чагыштыру. Текстны анализлау барышында автор билгеләмәләре, геройның исеме аша авторның аңа мөнәсәбәтен ачыклау. Әсәр героеның портретын, характерын аның эш-гамәлләре һәм сөйләме аша бирү.

Әдәби әсәр эчтәлеген сөйләүнең төрләрен (тулы, сайлап, кыскача – төп фикерне әйтү) үзләштерү.

Текстның эчтәлеген тулысынча сөйләү: бирелгән өзектәге төп фикерне ачыклау, кирәкле сүзләрне билгеләү, исем кушу, эпизодның эчтәлеген тулысынча сөйләү, һәрбер өлешнең һәм текстның төп фикерен билгеләү, һәр өлешкә һәм тулаем текстка исем кушу, тексттагы җөмләләрне атау, сорау җөмлә яки үзләре теләгән форма кулланып, план төзү.

Бирелгән өзек эчтәлеген сайлап сөйләү: геройга характеристика бирү (кирәкле сүзләрне тексттан сайлау), вакыйга буенча урынны сурәтләү (урынны сурәтләгән сүзләр, сүзтезмәләрне тексттан алып).

Төрле әсәрдәге охшаш ситуацияләрне, геройларны табу, чагыштыру.

***Уку материалы, фәнни-популяр һәм башка текстлар белән эш***

Әсәрнең исемен аның эчтәлегенә бәйле рәвештә аңлату. Уку, фәнни-популяр текстларның үзенчәлекләрен ачыклый белү. Риваять, легенда, мәсәл, миф, санамыш, әкият, тизәйткеч, үртәвеч, такмаза, бәет кебек әсәрләрнең гомуми үзенчәлекләен аңлау. Текстларга гади анализ алымнары белән таныштыру; сәбәп һәм нәтиҗә бердәмлеген ачыклау. Текстның төп фикерен, микротемаларны, төп һәм терәк сүзләрне табу. Текстны кабат укыганда эшчәнлек алгоритмын төзү. Терәк сүзләр, модель, схемаларга таянып, текстны кабат күздән кичерү. Эчтәлекне тулысынча һәм кыскача сөйләү (төп фикерне билгеләү).

***Сөйләм (аралашу культурасы)***

Сөйләм төре буларак диалог. Диалогик сөйләмнең үзенчәлекләре: сорауны аңлау, аларга җавап бирү; текст буенча сораулар куя белү. Әңгәмәдәшеңне бүлдермичә тыңлый һәм тикшерелә торган мәсьәлә буенча әдәпле итеп үз фикереңне әйтә белү (уку, фәнни, әдәби текст буенча). Текстка һәм шәхси тәҗрибәгә нигезләнеп, текст турында үз фикереңне әйтү. Дәрестән тыш аралашу вакытында сөйләм әдәбе нормаларыннан тайпылмау. Фольклор әсәрләре нигезендә милли этикет үзенчәлекләре белән таныштыру. Сүзлек белән эш (туры, күчерелмә, күпмәгънәле сүзләрне аерып алу), укучыларның сүзлек байлыгын максатчан тулыландыра бару.

Сөйләм төре буларак монолог. Автор текстына таянып, тәкъдим ителгән яки укытучы әйткән тема буенча зур булмаган текст (монолог) төзү. Сөйләмдә текстның төп фикерен чагылдыру. Фәнни-популяр һәм әдәби әсәрләрнең үзенчәлеген искә алып, укылган яки ишеткән текстның эчтәлеген төгәл сөйләп бирү. Көндәлек тормыштан, әдәби әсәрләрдән, сынлы сәнгать әсәрләреннән алынган тәэсирләрне тасвирлый белү, фикерләү, хикәяләү аша бирү. Чыгышыңны дөрес планлаштыра алу. Монологик сөйләмнең үзенчәлекләрен искә алып, синоним, антоним, чагыштыруларны урынлы куллану.

Укылган әсәрнең дәвамы буларак, телдән сочинение, рәсем яки бирелгән тема буенча кечкенә хикәя төзү.

***Язма сөйләм культурасы***

Язма сөйләм нормалары: эчтәлекнең әсәр исеменә туры килүе (тема чагылышы, геройларның характеры, вакыйга барган урын). Язма сөйләмдә телнең сәнгати сурәтләү чараларын: синоним, антоним, чагыштыруларны куллана белү. Бирелгән тема буенча хикәя, бәяләмә төзү.

***Балалар китабы белән эш***

Россиядә яшәүче төрле милләт халыкларының авыз иҗаты әсәрләре. XIX–XX гасырда яшәгән классик язучыларның (шул исәптән балалар язучыларының да) әсәрләрен өйрәнү. Чит ил һәм хәзерге көн язучыларының кече яшьтәге мәктәп баласы аңлый алырлык әсәрләрен бирү.

Төрле китаплар (тарихи, маҗаралы, фантастик, фәнни-популяр басмалар, белешмәлекләр, энциклопедияләр) һәм балалар вакытлы матбугаты белән танышу. Юмористик әсәрләр.

Балаларга тәкъдим ителә торган төп темалар: төрле халыкларның авыз иҗаты, Туган ил, табигать, балалар, җәнлекләр, яхшылык һәм яманлык.

***Әдәби әсәрләрне гамәли үзләштерү***

Укытучы ярдәмендә әдәби тексттан сәнгатьлелек чараларын: синоним, антоним, эпитет, чагыштыру, метафора, гиперболаларны табу һәм аларның әһәмиятен билгеләү.

Әдәби әсәр, әдәби образ, сүз сәнгате, автор (сөйләүче), сюжет, тема; әсәр герое: портреты, сөйләме, эш-гамәлләре, фикерләре; авторның әсәр героена мөнәсәбәте төшенчәләрен аңлату. Әсәрнең төзелеш үзенчәлекләре, сурәтләү (пейзаж, портрет, интерьер), фикер йөртү, геройның монологы һәм диалогы, композиция үзенчәлекләре турында күзаллау булдыру.

Чәчмә һәм тезмә сөйләмне тану, аеру; тезмә сөйләмнең үзенчәлекләрен (ритм, рифма) билгеләү.

Фольклор һәм автор әсәрләрен аеру. Әсәрләрнең жанр төрлелеге. Фольклор формасы буларак бишек җыры, үртәвечләр, мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар; аларны тану, аеру, төп фикерен билгеләү. Әкиятләр (хайваннар турында, тормыш-көнкүреш, тылсымлы) белән танышу. Әкиятләрнең әдәби үзенчәлеге, тел байлыгы, төзелеше. Автор әкиятләре.

Хикәя, шигырь, мәсәл жанрлары турында гомуми күзаллаулар, төзелеш үзенчәлекләре, сәнгати чаралары.

«Әдәби уку» программасы укучы эшчәнлегенә бәйле эш төрләрен күрсәтә. Дәресләрдә сәнгатьле уку, текстның эчтәлеген сөйләү һәм язу, сочинение язу, әзер темага телдән яки язма рәвештә текст әзерләү, картиналар белән эшләү, әсәргә нигезләп инсценировка эшләү, рольләргә бүлеп уку, уен кебек эш төрләрен куллану күз алдындатотыла.

Нәтиҗәдә, әдәби уку аша укучыларда сүз сәнгатен өйрәнүгә нигез салына, сөйләм культурасы булдыруга ирешелә. Бала әдәби текст укуның мәгълүмат чыганагы гына түгел, бәлки әхлакый һәм эстетик ләззәт алу чарасы булуына төшенә. Укучы текст аша милли әдәбият үзенчәлекләрен тоярга, әсәргә карата үз бәясен белдерергә тиеш була.

Башлангыч мәктәпне тәмамлаган укучы әдәби әсәрдән автор җиткерергә теләгән төп фикерне аерып чыгара белергә тиеш. Шулай ук аның лирик әсәрнең хис белдерү өчен хезмәт итүен аңлавын, әсәрдә автор һәм анда катнашучы геройларның фикер аерымлыкларын тоемлый алуы да күз алдында тотыла.

## 1 нче сыйныф

***<u>Әзерлек чоры</u>***

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчедән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү. Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау.

Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу.

***<u>Әлифба чоры</u>***

Сузык [а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө] авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп, иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү. Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.

Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.

Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү.

**Парсыз сонор тартык авазлар**

[м, н, л, р, й, ң] сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе: үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки тоткарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр.

Калын һәм нечкә яңгырашлы сүзләрдә сонор тартык авазлар әйтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хәрефләре (а, у, о, ы) белән (ма, му), нечкә яңгырашын нечкә сузык аваз хәрефләре (ә, и, ө, ү, э) белән белдерү. Сүздә һәр авазны аерып әйтү алымы. Рәсем һәм схема белән бирелгән сүзләргә аваз анализы. Анализлана торган сүз составына кергән аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат беләнбилгеләү.

Сүз башында һәм сүз уртасында |й] авазы

Я, е, ю хәрефләренең ике авазга [йа], [йә], [йы], [йә], [йу], [йү] билге булып килүләре: яра, ял, юл, куян, баян.

Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку. Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз формасын график формага күчерү процессын күзәтү.

Я, е, ю хәрефләрен куллану кагыйдәләрен үзләштерү. Бу хәрефләр кергән сүзләрне һәм иҗекләрне уку. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.

**Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар**

Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү: нечкәлек яңгырау, саңгырау ([д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ] һ.б.) парларның үзара мөнәсәбәтен ачыклау. Мәсәлән бар-бар, бар-пар һ.б. Өйрәнү тәртибендә басма хәреф формаларын үзләштерү.

Авазларында аерма булган сүзләрне, яңгырау һәм саңгырау тартык авазлардан башланган сүзләрне әйтеп карау, чагыштыру күнегүләре

Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку.

Башлангыч сүзне һәм **сүзнең авазын алмаштыру** яки **аваз өстәү юлы** белән ясалган яңа сүзләрне (бур-бура-буран), шулай ук ике яктан да бертөрле укыла торган (ана) сүзләрне уку. Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.

Аваз, иҗек, сүз, җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру.

**Аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ тан соң [й] авазы**

Язуда аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ һәм сузык аваз хәрефләре ярдәмендә [й] авазының язуда бирелешен (ь+е, я, ю; ъ+е, ю, я) аңлату. (Я, е, ю хәрефләре алдындагы иҗек калын сүзләргә (алъяпкыч) ъ билгесе, алдагы иҗек нечкә сүзләргә (дөнья) ь билгесе куелуын аңлатыла).

Аеру билгеләре һәм сузык аваз хәрефләре белән белдерелгән [й] авазлы сүзләрнең аваз анализы. [Й] авазы кергән сүзләрнең аваз схемасын уку, аны хәреф формасына үзгәртү, соңыннан башта иҗекләп, аннан соң орфоэпик дөрес итеп уку.

Ь, ъ билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү.

**Парсыз тарлык авазлар**

Парсыз [х, һ, щ, ц] тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергән иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.

***Әлифбадан соңгы чор***

Төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һәм таныш булмаган) сүзләрне укыганда иҗекләп укырга мөмкин. Җөмләнең тыныш билгеләренә карап җөмләләр арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикәяләү, сорау, тойгылы җөмләләрнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгән сорауларга тулы җавап бирү, сайлап алып эчтәлеген сөйләү, текстның башын, ахырын үзгәртү, аңа яңа исем бирә белү күнекмәләренә ия булу.Текстның 1)

башлам (вакыйга нәрсәдән башлана). 2) төп өлеш (катнашучы-геройлар белән нәрсә була), 3) йомгаклауга (нәрсә ничек тәгәлләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку. Текстта сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү.
Халык авыз иҗаты турында гомуми кузаллау. Авторларның булмавы, телдән сөйләм, практик-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практикүзләштерү.
Жанрлар турында гомуми кузаллау булдыру: хикәя, шигырь. Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү.
Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрь матурлыкны тоя белергә өйрәтә. Рифма белән танышу: аны таба, куллана белергәкүнектерү.
Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел кузаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм төшенчәсе бирү.
Әсәрләр: Татар халык әкияте “Аю белән өч кыз”, Р.Миңнуллин “Шүрәлесез урман”, Ш.Галиев “Курыкма, тимим”, Г.Тукай “Туган тел”, Р.Харис “Сине көтә тыныч таң”, М.Мәһдиев “Авылдан кучтәнәч”
**Милли-региональ компонент**
Республика, туган як турында мәгълүмат бирү. Татар халык авыз иҗаты белән танышу. Татар язучылары иҗаты белән танышу.

**2нче сыйныф**

**Халык авыз иҗаты . Әкиятләр**
Хайваннар турында әкиятләр. Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.
Тылсымлы әкиятләр. Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар (эченнән гаскәр чыга торган таяк, төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше күзенә күрсәтми торган бүрек,җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч Һ.6.), герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак, көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар (җәнлекләр: этәч, бүре, аю, куян, шулай ук убырлы карчык Һ.6.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргәәверелүе).
Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру). “Батыр этәч” “Әтәч патша” ."Бүдәнә белән төлке”. ”Аю белән төлке” ; “Гөлчәчәк” , .”Өч кыз” татар халык әкиятләре.
**Мәкальләр.**
Мәкальләр – халыкның тормыш тәҗрибәсеннән тупланган акыллы сүзләр белән таныштыру.Мәкальләрнең мәгънәсен аңлату.
**Автор әкиятләре**
Тылсымлы шигъри әкиятләр, аларда халык әкиятләре белән сюжет бәйләнеше, композиция үзенчәлеге. Автор әсәрләрендә һәм халык әкиятләрендәге сюжет кулланылышы (капма-каршы ике дөнья, булышчылыр, тылсымлы төсләр). Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Сәнгатьле уку, сүзлек эше, эчтәлек сөйләү, төп геройларга характеристика бирү.
Г.Тукай “Су анасы”, “Кәҗә белән Сарык “ әкиятләре; М. Гафури “Тавык белән үрдәк” шигъри әкияте, “Тавык нигә суда йөзә алмый?” риваяте; Г.Вәлиева “Су әкияте”; Э.Шәрифуллина “Алтынбалык”.
**Әдәби жанрлар**
**Шигърият**
Шигъри формада язылган әсәрләр (Р. Вәлиева, Ф. Яруллин, Җ. Дәрзаман, Йолдыз). Йолдыз “Белмим” Р.Вәлиева “Замана баласы” Ф.Яруллин “Эшнең аның берние юк” Җ.Дәрзаман “Солдат булдым”.

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).
Г.Тукай, Н.Ахунова, Р Вәлиева, Р.Файзуллин, Э.Шәрифуллина әсәрләре; Г.Тукай "Буран"; кыска шигырьләр; Н.Ахунова "Хоккулар"; Э.Шәрифуллина "Алтын балык". Г.Морат, Г.Хәсәнов, Ә.Еники, Р.Мингалим, Йолдыз, Ф.Сафин, М.Фәйзуллина, Р.Газизов, С.Урайский, Л.Лерон, М.Галиев,М.Шабаев, Э.Шәрифуллина, Г.Мөхәммәтшин, Р.Вәлиева, Р.Корбан әсәрләре.
Әсәрләрне анализлый белү, рәссамнарның матурлыкны буяулар белән бирү үзенчәлекәрен белү, картиналардагы матурлыкны күрә белү, табигатьнең матурлыгын күрә белү.

**Хикәя**

Жанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте.
Л. Лерон, И.Туктар, Р. Миңнуллин әсәрләрен уку. Л.Лерон "И ямьле дә соң дөнья!". И.Туктар "Урман букеты". Р.Миңнуллин "Чыршы әйләнәсендә". Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).
Р.Харис,Ш.Галиев,Ф.Садриев,Р.Миңнуллин,Р.Сарби,Г.Юнысова,Г.Гыйльманов,Н.Арсланов,М.Әгъләмов,М.Шабаев,Н.Мадьяров,З.Минһаҗева,Г.Шаһи,Ф.Зыятдинов, Р.Фәйзуллин,Г.Тукай,Р.Хафизова,Җ.Дәрзаман,Б.Рәхмәт,Р.Корбан,Л.Лерон,Ә.Моталлапов, Г.Афзал,Р.Вәлиева әсәрләрен уку.
Үзбәя бирә белү, табигатьне җанлы итеп күрә белү, табигатьнең кабатланмас кыйммәтен аңлый белү, дөньяга шигъри караш белән объектив караш арасындагы аерманы аера белү, гади генә предметлардан да тылсым күрә белү, бер тамчы суда да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген аңлау, бинокль аша да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген белү, матурлыкны "Күңел күзе" белән күрә белү, күзәтүчән, игътибарлы һәм хыялый була белү, төрле ситуациядән чыгу өчен оптимистик карарлар кабул итү, тема һәм фикер уртаклыгын таба белү, авторның төп фикерен аңлый белү.

**Библиографик культура**

Газета-журналларның ни өчен вакытлы матбугат дип аталуын, яңалык белән гайбәт арасындагы аерманы аера белү. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Татар телендә чыга торган балалар журналларын белү, журналларда һәм газеталарда ориентлаша белү.

**Милли-региональ компонент**

Татар халык авыз иҗаты белән танышу. Татар язучылары иҗаты белән танышу. Татарстанда чыга торган балалар газета-журналлары белән танышу.

**3нче сыйныф**

**Әдәби жанрлар.**

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау.
Әйләнә-тирә дөнья матурлыгының шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуына инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы ( тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Әкият һәм хикәя жанрының композиция үзенчәлеген ( күзәтүләр аша ) аңлату. Укучы- тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырыпсөйләү.
Б. Рәхмәт "Иң күңелле чак", Р. Хисмәтуллин «Июль аланы», Р. Вәлиева "Җәй һәм бала", М. Галиев «Җиләктән кайтканда», М. Мирза "Көздә бермәл", "Көз", "Болыт", Б. Рәхимова «Шук болытлар, батыр җил, якты кояш», М. Гафури "Болын", Н. Дәүли «Бала болыт», Р. Корбан "Көз нигә моңая", Р. Вәлиева "Яңгыр, яу!", "Китмә әле, бераз тор", Йолдыз "Салават күпере", М. Әлимбаев "Салават күпере", Л. Лерон «Яңгырның ял көне», М. Җәлил "Яңгыр", Р. Мингалим «Август каеннары»,Ш.Маннур"Көзгеурманда",З.Туфайлова«Яфракява»,Х.Әюпов«Әбиләрчуагы»,К.Тәхау"Көзгеурман",Р.Әхмәтҗан"Соңгыяфрак",М.Мазунов
«Карап торам», Г. Хәсәнов «Кыр казы», Г. Бәширов «Ана каз белән ата каз һәм аларның уникe бәбкәсе», Н. Гыйматдинова «Казлар», Г. Остер «Серне ачты», В. Хәйруллина "Тәрбияче попугай", Н. Сладков "Күзалдавычлар", Р. Әхмәт "Сыкы", Н. Сладков "Кем остарак", Р. Корбан "Мәктәпкә озату бәйрәме", Г. Паушкин "Кыш", Г. Рәхим "Безнең тауда", Н. Әхмәдиев "Чишмәгә суга барам", К. Кәримов "Кышкы мәтрүшкәләр", Н. Гыйматдинова Сарбай", Л. Лерон "Хыял", Йолдыз "Антенналы бәрәңге", Л. Лерон "Хыялый Акбай", Ә. Габиди "Тере антенналар", Л. Лерон "Мәче малае Шукбай", "Шукбай балык тота", "Хат", Ф. Мөслимова "Хыялый", З. Гомәрова "Хыялларым", Б. Рәхмәт "Ничек өйрәнергә", Р. Фәйзуллин "Тугайда", А. Әхмәтгалиева "Болытта җиләк үсә", Ф. Садриев " Юкка көттеләр", А. Гыйләҗев "Суык", А. Аланазаров "Дустымны эзлим2, В. Хәйруллин "Кем булам", Йолдыз "Этем югалды бүген", Р. Гыйзәтуллин "Батырлык", Г. Рәхим "Иске самавыр торбасы, Р. Фәйзуллин "Онытма син!", М. Мирза "Идел-йорт", "Без бабайсыз үстек", Р. Рәкыйпов "Мин яратам сине, Татарстан!", Л. Шагыйрьҗан "Сөембикә манарасы", В. Нуриев "Хуҗалар тавы", Х. Туфан "Казан", З. Гомәрова "Батырлар хакында", Р. Харис "Сугыш турында сөйләшә картлар","Игенче җыры", Г. Гыйлман "Нәсел агачы", "Дәү әтинең әтисе", "Универсиада", В. Хәйруллина "Хозурлык һәм горурлык", Ф. Кәрим "Ант", Ватаным өчен", М. Җәлил "Кичер, илем!", Х. Халиков "Рәхмәт сезгә, ветераннар!", В. Нуруллин "Бүреләр, үгез һәм без", С. Рәхмәтуллин "Сандыктагы хәзинә", Р. Мәннан "Без музейга барабыз", Г. Ахунов "Канатлар кая илтә?", Г. Моратов "Корыч шулай чыныкты", И. Юзеев "Матурлыкны гына алып кит", М. Рафиков "Җир куены", Г. Бәширов "Безнең Татарстан", Р. Фәйзуллин "Нефть", "Безнең КамАЗ", Йолдыз "Спортчы Шүрәле", Р. Миңнуллин "Кунакка килегез", Р. Вәлиев "Барысын да яратам", Ш. Маннур " Яратам", Р. Вәлиева "Чыпчык", М. Хөсәен "Китап", С. Урайский "Туган ил", А. Гыймадиев "Шәмси маҗаралары", Н. Кәримова "Авылым җыры", В. Нуриев "Кем катырак суга?", Р. Вәлиева "Яңгыр белән Кояш", Г. Сабитов "Тәүге шатлык", Ә. Баянов "Тургай", Н. Гыйматдинова "Болын патшасы", А. Әхмәтгалиева "Безнең чишмә", Г. Бәширов "Беренче кар", Н. Сладков "Кышкы җәй", М. Мазунов "Яңа карлар ява", И. Солтан "Кар ник шыгырдый?", И. Солтан "Кар ник ява?", Р. Мәннан "Кыш килә", Ф. Зыятдинов "Муллык билгесе", М. Мирза "Кышның китәсе килми", Р. Миңнуллин "Кар бәйрәме", С. Урайский "Кыш шатлыгы", Р. Вәлиева "Каникул вакытында",

Ш. Галиев "Иншаның файдасы", "Сүзләре һәм үзләре", В. Нуриев "Инша", Л. Лерон "Иртән уянасың килмәсә", Сүз тыңлыйсың килмәсә", "Инша", Р. Вәлиева "Көчле укучы", "Сыер эзләгәндә", К.Тәңрекулиев "Эшчән" , Гельды", И. Юзеев "Хатасыз ничек язарга?", Р. Миңнуллин "Хаталар өстендә эшләү", Г. Морат "Үскәч кем булырга", "Тиргиләр", Р. Низамова "Табигать күренеше", Р. Фәйзуллин "Ничек яхшы булырга?", Йолдыз "Ике җаваплы табышмак", Н. Кәримова "Кое чыпчыгы", З. Туфайлова "Трай", А. Алиш "Утлы йомырка", Р. Вәлиев"Минеке".

Халык авыз иҗаты әсәрләре

Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөри торган хайваннар турындагы әкиятләргә карата гомуми күзаллау булдыру. Әкиятләрнең гасыр дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату. Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы,хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау булдыру.

Әфган халык әкияте: “ Иң яхшы дару”, “Табышны ничек бүләргә?”, “Кабартма”; Уйгур халык әкияте: “Тылсымлы китмән”; Инглиз халык әкияте: “Көрән төстәге пингвин баласы”; Монгол халык әкияте: “Әтәч таңда нигә кычкыра?”; Манси халык әкияте: “Куянның колагы нигә озын?”; Кабарда халык әкияте: “Җәнлекләр патшасы”; Венгр халык әкияте: “Комсызлык бәласы”; Африка негрлары әкияте: “Сырны ничек бүлгәннәр?”; Эстон халык әкияте: “Куянның ирене нигә ярык?”; Эвенк халык әкияте: “Әтәч нигә кычкыра?”; Казакъ халык әкияте: “Юмарт дөя”; Нугай халык әкияте: “Карт һәм су анасы”; Норвегия халык әкияте: “Кабартма”; Алман халык әкияте: “Сандугач белән Аю”; Каракалпак халык әкияте: “Җәй белән Кыш нигә күрешми?”; Латыш халык әкияте: “Шайтанга ничә яшь?”; Литва халык әкияте: “Итагатьле мәче”, Л. Лерон “Әкияти башламнар”, Йолдыз “Охшашлык”, Э. Шәрифуллина “Әкияткайда?”

**Автор әсәрләре**

Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмасатурлыгы.

Ф. Яруллин “Тылсымлы ачкыч”, Р. Мингалим “Уйларга кирәк”, Р. Харис “Берсе калсын иде”, Р. Вәлиева “Кышкы ямь”, Йолдыз “Белмәгәнен белми”, М. Мирза “Язның тәүге көннәре”, Г. Хәсәнов “Корташар”, “Гөблә”, “Май”, Ә. Рәшит “Яшенле яңгыр”, Г. Гыйлман “Көзге урман”, Ф. Садриев “Белемле әби”, Х. Халиков “Витаминлы аш”, Н. Гыйматдинова “Дару”.

**Мәсәлләр**

Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж.Лафонтен, И.Крылов, татар мәсәлчеләре К.Насыйри, Г.Тукай,М.Гафури, Г.Шамуков, Ә.Исхак һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнү. Төрле халык мәкальләре . Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану. Мәсәл һәм әкиятне чагыштыру. Мәсәлләрнең хайваннар турындагы әкиятләрдән килеп чыгуы. Мәсәлләрнең төп асылы, эчтәлеге. Мәсәл моралендә мәкальләр куллану. Мәсәлләрнең тәрбияви роле.

Эзоп “Давыл белән Кояш”, Г. Тукай “Җил илә Кояш”, Н. Исәнбәт “Ябалак белән Чыпчык”, татар халык әкияте “Ябалак белән чыпчык”, Ф. Яруллин “Мактану бәласе”, К. Насыйри “Төлке белән Әтәч”, М.Гафури “Мәймүн белән күзлекләр”, “Чикерткә белән кырмыска”, Г. Тукай “Көзге белән маймыл”, Г.Шамуков “Көзге белән Маймыл”, Т. Яхин “Карга белән Төлке”, Ф. Яхин “Сыр бәласе”, Г. Шамуков “Карга белән Төлке”, Ф. Яруллин “Хәйләкәр куян”, М. Гафури “Ике белән бака”, В. Гаршин “Ил гизүче бака”, В. Радлов “Карганың бәласе”, Л. Толстой “Зирәк Чәүкә”, К. Насыйри “Комсыз эт”, С. Шакир “Таш белән Кырмыска”, Ә. Исхак “Карт Имән белән яшь егет”, М. Гафури “Ике чебен”, М. Саттар “Кырмыска белән тирес корты”, Г. Тукай “Яшь агач”, Г. Тукай “Төлке белән йөзем җимеше”, Ә. Исхак “Төлке белән виноград”, Г. Вәлиева “Заман әкияте”, Г. Тукай “Аккош, Чуртан һәм Кыскыч”, И. Крылов “Аккош, Чуртан һәм Кысла”, М. Гафури “Кәҗә белән Төлке”.

Библиографиккультура

«Эчтәлек» бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китап¬тан таба белү; кече яшьтәге мәктәп баласының дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файда¬лану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.

Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән кар¬тинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү . Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасынүстерү.

**Милли-региональ компонент**

Туган ил, Ватан турында хикәяләр уку. Халыкның үткән тарихы, тарихи һәйкәлләре, тарихи шәхесләре белән танышу.

**4 нче сыйныф**

**Халык авыз иҗаты.**

**Мифлар турында гомуми күзаллау булдыру.**

Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы. Тотем хайван һәм үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

**Тылсымлы әкиятләр.**

Дөнья турында борынгы күзаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы. Тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә. Максатка ирешү юлы (тылсымдөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы.) Халык әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.

**Риваять һәм легендалар.**

Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар. Аларның килеп чыгышы.Риваять һәм легендаларда бирелгән вакыйгаларның әкиятләрдәчагылышы.

**Автор әкиятләре.**

Автор әкиятләренең халык әкиятлре белән охшашлыгы (жанр һәм сюжет). Халык әкиятлрендәге тылсым юлы белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**

Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Символик төшенчәләр. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.

**Хикәя.**

Хикәя жанры турында күзаллау формалаштыруны дәвам итү. Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел бирәмлекләре.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында күзаллау формалаштыру.**

Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлауга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерларында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгын шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуын инандыру. Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.

Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Әсәр авторлары турында.**

Шагыйрь, язучы, рәссамның биографиясе.

а) әсәрдә авторлар кичереше; ә) автор күзәтүләренең чагылыш; б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**

Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру.**
Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру *( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку)*. Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.
**Укыла торган әсәрләр**
**Халык авыз иҗаты.**
“Җир ничек яралган?” (легенда), “Күкнең күтәрелүе (хикәят), “Айдархан һәм сәхабәләр, (легенда), “Пәйгамбәрнең тууы һәм аның балачагы”, “Абага чәчәге (хикәят), “Ак бүре”(риваять), “Кырык кыз”( риваять), “Мәрҗан каласы һәм унике кыз” (хикәят), “Дөнья яратылу турында” (миф), “Хапи алла турында” (миф), “Чыршы ни өчен мәңге яшел?” (легенда), әкиятләр: “Ак байтал”,“Ак бүре”, “Еланнар патшасы Шаһмара”, “Үги кыз” , “Ике кыз”, “Бумеранг”(Австралия халкыәкияте).
**Борынгы язучылар һәм татар әдәбияты классиклары**
Кол Гали “Кыйссаи Йосыф”. Г. Тукай : “Таз”, “Яз галәмәтләре”. Дәрдемәнд: “Гали”. З. Ярмәки: “Иртә”, “Ак каен”. М.Җәлил: “Дару”.
К.Насыйри. “Каз итен коймакка төреп,каймакка манып ашау”. Н.Исәнбәт: “ Кышкы төндә”, “Туган ил”, “Өч матур сүз”. Ш.Бабич: “ Тын төн”, “Габдулла әфәнде Тукай”. А. Алиш. “Сертотмас Үрдәк”. Г.Кутуй. «Яшен”. Ш.Галиев: «Кол Галигә”, “Алсу дөнья”, “Җирдә миңа ни кирәк?”, “Урман ява”, “Тукран сые”.
Г.Ибраһимов: “ Укудан кайткач”. Г.Галиев.” Бибкәй аланы”. Ф.Әмирхан. “ Кечкенә хезмәтче”. К.Нәҗми: “Нәсимәнең беренче эш көне”.
З.Бәшири: “ Бер асрауның аһ-зары”. Н.Думави: “ “Беренче кар”, “Ятим бала”. М.Мәһдиев: “Бәхилләшү”. С.Хәким: “ “Яратам мин”, “Тегермән стенасындагы язулар”.
Ә.Фәйзи :”Асрарга бала бирәм”. Ф.Хөсни:”Малай белән солдат”. Ш.Рәкыйпов: “ Төнге очыш”. И.Туктар: “Букет”, “Бер каен үсә”. Г.Хәсәнов: “ Аккош”, “Абага”.
Г.Сабитов: “Кадерле ул туган як!”, “Чәчәк нигә боекты?”. Н.Арсланов: “Халкыма”. Җ.Тәрҗеманов: “Шуктуган”, “Тукран малае Шуктуган”.
Л.Ихсанова : “ Шомырт чәчәкләре ак кына”. Ф.Яруллин: “Буар елан”. М.Әгъләмов: “Матурлык минем белән”. Зөлфәт: “Кыз тавы”.
С.Шакир: “ Ландыш чәчәге”. Р.Хафизова: “Кирлемән”. Г.Латыйп: “Минем нәсел”. Р.Гыйззәтуллин: “Язгы моң”. К.Тимбикова: “Бану әби сабагы”.
К.Сибгатуллин: “Чыпчык”, “Бөтен кеше бүген шундый әйбәт”. Роб.Әхмәтҗанов: “Безнең шигырь”. Р.Хисмәтуллин: “Аһ. Бер китсә кирегә...”
**Рус язучылары:**
Л. Толстой: “Слива төше”. Н. Сладков: “Тыштан ялтырый. эчтщн калтырый».
**Татар язучылары һәм шагыйрьләре (бүгенге көн язучылары)**
Р. Миңнуллин: “Иртән иртүк”, “Атказанган сандугач”, “Машина тавышлы көчек турында кечкенә әкият”, “Сабантуйда”, “Татарларым”, “Минем телем”, “Утыз Имәнине укыганда туган уйлар”. Р. Фәйзуллин: “Быелгы яз”, “Минем әти”. Х.Камалов: “ Археолог”. Ә.Рәшит: “ Нәсел агачы”. К.Булатова:”Кичә генә”, “Шушы яктан, шушы туфрактан без”. Җ.Дәрзаман: “Бөҗәкләр белән сөйләшү”. Р. Вәлиева: “Изгеләр тавы”, Энҗе чәчәк”. “Бөтен дөнья ак кына”,“Онытма!”.
Р. Вәлиев: “Кошлар кайта”, “Кайтчы, Сөембикә”, “Эт кояшы” (өзек), “Ватаным”. Н. Әхмәдиев: “Хәерле иртә”. И.Гыйлаҗев: “Тутыкмас тотка”, “Охшашлык”.
Р.Харис: “Татарстан әләме”, “Зөләйха”, Ак карлар арасында”, “Елмай”, “Туган җирем”, “Фронтовиклар”. Л. Лерон: “Кыхмырый, Мыхмырый һәм Шыхмырый”.
Э. Шәрифуллинаб “ Табигатьнең бер бөртеге”, Без татар балалары”, “Тормыш яме”. Г. Гыйльманов: “ Чишмәгә бардык”, Кайтаваз”, “Курай”, “Җавапсыз легенда”, “Минем исемем – Бүрек”. В. Нуриев: “Ачуланма инде. Илһам!” Г. Рәхим:”Көз йөри”, “Көзге моң”, “Көзге урман”, “Песнәк”, “Апрель”.
Р. Корбан: “Көз нинә моңлы?”, “Ярдәм итик”, “Курай”. Йолдыз: “ Очрашу”. Р.Мингалим: “ Бүген төнлә күккә кара”. Батулла: “ Су ияләре”(әкият), “Терек-терек кырмыска”, “Салават күпере кайда йоклый?” В.Хәйруллина “ Хәерле көн”, “Алмаштыру”,“Наз”, “Чикерткә”. М.Мирза: “ Көз”, “Балачак хатирәсе”.
Ф.Бәйрәмова: “Кара пулат”. Мөҗәһит: “Бер яфрак зары”. Д.Гайнетдинова: “Исәнме, яңа көн”, “Батыр Хәбир”. Л.Гыймадиева: “Кара урман, караңгы төн”.
Н.Сәйяр: “ Айсылу”. Р.Рахман: “ Кесәл”. Н.Каштан: “ Әрем исе”. Г.Вәлиева: “Кызыктырсалар да”, “Карт алаша колагы”. Ф.Тарханова: “Без бәлеш пешерәбез”, “Килде пилмән ашыйсы”. И Нәбиуллина: “Тәмле тел”. Ф. Мәҗитов: “Яңгыр кызы Гөлтамчы”. Г.Мөхәммәтшин: “ Туган як”. М.Галиев: “ Туганяк”.
Г.Морат: “ Чит тел”. С.Гаффарова: “Көз”. Р.Зәйдулла: “Кол Гали”.

**Милли-региональ компонент**

Халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру. Төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу. Милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру.

**2. Һәр теманы үзләштерү өчен бирелгән сәгать санын күрсәтеп, тематикпланлаштыру.**

**1 сыйныф.**

| Бүлек исеме | Темалар | Сәг саны |
|---|---|---|
| Әлифба алды чоры | Сөйләм. Аралашу алымнары.Җөмлә. Җөмләнең график схемалары.Сүзләр. Сүз басымы.Иҗек. Сузык авазлардан гына торган иҗекләр. Аваз. Аваз һәм хәрефне аеру. Сузык һәм тартык аваз. Авазларны сөйләмдә дөрес әйтү. Сөйләм авазлары.<br>Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Хәреф һәм аваз турында төшенчә.Сүзгә аваз анализы ясау. | 2 |
| Әлифба чоры | Сузык авазлар, хәрефләр: а,ә,ы,э,и,у,ү,о,ө,я,ю,е.<br>Тартык авазлар:н,л.р,м,й,ң,д,т,з.с,г,к,в,ф.б.п,ж,ш,җ.ч.х,һ.щ.ц. Калынлык һәм нечкәлек билгеләре. | 38 |
| Уку. Сөйләм үстерү. | Шигырь һәм проза. Шигъри һәм чәчмә әсәрләр турында го¬муми күзаллау булдыру. Әдәби әсәрнең исеме, авторы (язучы, шагыйрь), халык авыз иҗатында билгесезлек (авторы юк).<br>Халык авыз иҗаты һәм әдәбият. Халык авыз иҗаты ту¬рында гомуми күзаллау булдыру. Авторның булмавы, телдән сөйләм, практик уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әй¬ләнмәле әкият кебек формаларын практик яктан үзләштерү.<br>Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе).<br>Әсәрнең эмоциональ тоны. Юмористик һәм җитди характер¬дагы әсәрләр. Әсәрләрне китаптан кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерны чагылдыра белү. Тавыш төсмерләре: интонация, тон, тавыш көче, тембр, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләр, ымнарны дөрес бирә алу.<br>Әдәби сәнгатьлелек чаралары. Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел күзаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: «рифма», «ритм» төшенчәсе бирү.<br>Әдәби жанрлар. Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру.<br>Хикәя. Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү, әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү.<br>Шигырь. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрьләрнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүләренә инандыру. Рифма белән танышу: аны таба һәм куллана белергә күнектерү. | 26 |

| | | |
|---|---|---|
| | Библиографик культура. Дәреслектә җиңел генә ориентла¬шырга өйрәтү: «Эчтәлек» битеннән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп табу.<br>Уку күнекмәләре. Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дө¬рес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү.Татар халык авыз иҗаты. Санамышлар. Табышмаклар. Ф.Яруллин “Саескан”.С.Сәүбанова “Керпе нигә курыкмый?” Эндәшләр.Тизәйткечләр. Такмазалар.Р.Газизов “Беләсезме”, “Уйныйбыз”, “Кар чакыру” Охшаш яңгырашлы сүзләр.М.Галиев “Кайтаваз” , Ш.Галиев “Чагу”,Таяк”,”Шауламагыз,әти йоклый”, Р. Вәлиев “Кайтаваз кайда яши?”<br>Рифма һәм шигырь мәгънәсе. Л.Лерон “Буталмышлар илендә”, “Сабантуй галәмәтләре”<br>Шаян шигырьләр. Р.Корбан “Көчек”, “Яңгыр яуганда”. Ф.Яруллин “Хыялый чебеш”, “Сабантуй”.<br>Чылбыр әкиятләр. “Аю белән өч кыз”әкияте, “Песәй”әкияте.<br>Әкиятләр.”Абый белән эне”,”Кем нәрсә ярата?” Х.Халиков ”Бии белмәгән аю”, Х.Туфан “Буталмыш әкият”<br>Яңгыравык шигырьләр. Р.Бәшәр “Бал корты”, “Авазлар”.Ф.Яруллин “Черкиләр җыры”, Р.Бәшәр “Авылга кайту”<br>Поэзиядә һәм прозада яңгыравык сүзләр. Э.Шәрифуллина “Бәйрәм ашы-кара каршы”, Р. Фәйзуллин “Хыял”, “Сүзне сүз ашаган”.<br>Урман мәктәбендә. Х.Халиков “Әллә ул да белә микән?”Песи үләне”, “Каен җиләге”, “Тузганак”, “Энҗе чәчәк”. Р.Вәлиева “Урман әкияте”. Малайлар, кызлар турында. Р.Миңнуллин “Үзебез генә калгач”, Р. Миңнуллин “Малайлар бәйрәме иде”, Х.Халиков “Кушамат”, Ф. Зиятдинова “Мин андый малай түгел”, Ф.Мөслимова “Хәйләкәр каләм”, Йолдыз “Урынсызга әрләмә”<br>Поэзиядә юмор хисе. Б.Заходер “Өтерне кая куярга”, Ш.Галиев “Курыкма, тимим”, “Шәвәли сере”.”Мин”, “Керпе таптык”<br>Әдәбиятта фантазия. Р.Кутуй “Төнге әкият” И.Туктар “Җем-җем! ..Чвик”<br>Дөньяны кем ничек күрә? Р.Миңнуллин “Шүрәлесез урман”, Х.Халиков “Әгәр күрә белсәгез” В.Хәйруллина “Сакчы Шүрәле”, М.Галиев “Шүрәле һәм җил”<br>Шагыйрь нәрсә күрә, нәрсә ишетә? Р.Вәлиева “Кыңгырау чәчәк”, Х.Халиков “тартар белән сөйләшү”, “Аксак кәҗә”, Р.Корбан “ Сукмак”, “Шүрәле рәхмәт әйткән” , Р. Хисмәтуллин “Хәерле иртә” | |
| Барлыгы | | 66 |

**Әдәби уку 2 сыйныф**

| | | |
|---|---|---|
| **1. Белдекле Керпедә кунакта** | **21** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Хайваннар турында әкиятләр. Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.Тылсымлы әкиятләр. Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар (эченнән гаскәр чыга |

| | | |
|---|---|---|
| | | торган таяк, төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше күзенә күрсәтми торган бүрек,җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч Һ.б.), герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак,көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар (җәнлекләр: әтәч, бүре, аю, куян, шулай ук убырлы карчык Һ.б.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелүе). Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру).<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, эчтәлек сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>Дәреслекнең төзелешен белергә,әкиятләрнең автор һәм халык әкиятләренә бүленешен аерырга,эчтәлек битендә ориентлаша алырга, халык һәм автор әкиятләрен аерырга, иллюстрацияләр аша әкиятләрне танырга,әкиятләрне мәгънәви кисәкләргә бүлә белергә,кыен хәлләргә калганда авырлыкларны җиңә белергә, әкиятләрнең үзенчәлекләрен мөстәкыйль рәвештә күрә белергә,укыган әкиятләр арасыннан тылсымлыларын аера белергә,җәнлекләр турындагы татар халык әкиятләрен башка халык әкиятләре белән чагыштырып үзенчәлекле якларын таба белергә,автор әкиятләре белән борынгы әкиятләрне аера белергә.<br>**Контроль төрләре:** телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар халык авыз иҗаты белән танышу |
| **2. Белмәмештә кунакта** | **4** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Шигъри формада язылган әсәрләр (Р. Вәлиева, Ф. Яруллин, Җ. Дәрзаман,Йолдыз) .<br>Йолдыз “Белмим”; Р.Вәлиева “Замана баласы”; Ф.Яруллин “Эшнең анык берние юк”; Җ.Дәрзаман “Солдат булдым”.<br>Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, эчтәлек сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:** Әкиятләрнең тәрбия бирү өлкәсендәге мөһим ролен аңларга,кабатлану алымын таба белергә,мәзәк маҗара белән әкиятләрнең охшашлыгын күрә белергә, әкиятләрнең тәрбия бирү өлкәсендәге мөһим ролен аңларга, табигатьнең бербөтен булуын, аны сакларга кирәклеген белергә, үз эшләрен анализлый белергә, күзәтүчән, игътибарлы була белергә,татар халкы белән япон халкы арасындагы уртак якларны күрә белергә, рәсем һәм шигърият арасындагы бердәмлекне күрсәтә белергә, хыялланырга, матурлыкны күрә, аңлый белергә,үзеңдәге тискәре сыйфатларны бетерергә кирәклеген аңларга.<br>**Контроль төрләре**: телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. |

| | | |
|---|---|---|
| **3. Укымышлы Ябалак янында** | **4** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Г.Тукай, Н.Ахунова А., Р.Вәлиева, Р.Файзуллин, Э.Шәрифуллина әсәрләре; Г.Тукай ”Буран”; кыска шигырьләр; Н.Ахунова “Хоккулар”; Э.Шәрифуллина “Алтын балык”<br>Җанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте.<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:** күзәтүчән, игътибарлы була белергә,үзеңдәге тискәре сыйфатларны аңлау һәм бетерү өстендә эшләргә,хезмәтнең кеше тормышындагы ролен ачыкларга,күзәтүләр аша гомумиләштерергә,әсәрләрдән тиешле урыннарны таба белергә, хыялланырга, матурлыкны күрә, аңлый белергә,хыял белән үзең телә́гән дөньяны бәйли белергә.<br>**Контроль төрләре:** телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. |
| **4.Аю өнендә** | **4** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Л. Лерон, И.Туктар, Р.Миңнуллин әсәрләрен уку.<br>Л.Лерон “И ямьле дә соң дөнья!”; И.Туктар “Урман букеты”; Р.Миңнуллин “Чыршы әйләнәсендә”.<br>Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,<br>тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).<br>**Эш формалары**: практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>Кеше һәм табигать бергәлеген, дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзалларга,әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандырырга. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитетларны аерырга, автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлыкны, чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белергә, аңлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерергә (темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).<br>**Контроль төрләре:** телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. |
| **5. Күрү ноктасы** | **21** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Р.Харис,Ш.Галиев,Ф.Садриев,Р.Миңнуллин,<br>Р.Сарби,Г.Юнысова,Г.Гыйльманов,Н.Арсланов,М.Әгъләмов,М.Шабаев,Н.Мадьяров,З.Минһаҗева,Г.Шаһи,Ф.Зыятдинов,Р.Файз |

| | | |
|---|---|---|
| | | уллин, Г.Тукай,Р.Хафизова,Җ.Дәрзаман,Б.Рәхмәт,Р.Корбан,Л.Лерон,Ә.Моталлапов, Г.Афзал,Р.Валиева әсәрләрен уку.<br>Үзбәя бирә белү, табигатьне җанлы итеп күрә белү,табигатьнең кабатланмас кыйммәтен аңлый белү,дөньяга шигъри караш белән объектив караш арасындагы аерманы аера белү. Гади генә предметлардан да тылсым күрә белү,бер тамчы суда да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген аңлау, бинокль аша да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген белү,матурлыкны “Күңел күзе” белән күрә белү,күзәтүчән,игътибарлы һәм хыялый була белү,төрле ситуациядән чыгу өчен оптимистик карарлар кабул итү,тема һәм фикер уртаклыгын таба белү,авторның төп фикерен аңлый белү.<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>«Эчтәлек» кә карап кирәкле әсәрне китаптан таба белергә, өй, мәктәп китапханәләреннән файдаланырга, фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләргә.<br>Пейзаж, натюрморт, портрет жанрларын гамәли рәвештә таба белергә, хыялланырга, матурлыкны күрә, аңлый белергә,хыял белән үзең теләгән дөньяны бәйли белергә. Үзбәя бирә белергә,табигатьне җанлы итеп күрә белергә,табигатьнең кабатланмас кыйммәтен аңлый белергә,дөньяга шигъри караш белән объектив караш арасындагы аерманы аера белергә, гади генә предметлардан да тылсым күрә белергә,бер тамчы суда да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген аңларга, бинокль аша да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген белергә,матурлыкны “Күңел күзе” белән күрә белүергә,күзәтүчән,игътибарлы һәм хыялый була белергә,төрле ситуациядән чыгу өчен оптимистик карарлар кабул итә белергә,тема һәм фикер уртаклыгын таба белергә,авторның төп фикерен аңлый белергә.<br>**Контроль төрләре:** телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. |
| **6. Балалар газета-журналлары** | **4** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Газета-журналларның ни өчен вакытлы матбугат дип аталуын,яңалык белән гайбәт арасындагы аерманы аера белү. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация,тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау. Татар телендә чыга торган балалар журналларын белү. Журналларда һәм газеталарда ориентлаша белү.<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштырырга(интонация,тон, темп саклап кычкырып уку),автор бирергә теләгән картинаны күзалларга, эчтән укый белергә күнегергә, чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча укырга,укылган әсәргә анализ ясый белергә,татар телендә чыга торган балалар журналларын белергә. Журналларда һәм газеталарда ориентлаша белергә.<br>**Контроль төрләре:** телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты**:Балалар газета-журналлары белән танышу. |

| | | |
|---|---|---|
| 7. **Шагыйрь өчен табигать-серле һәм җанлы дөнья** | **4** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Г.Морат, Г.Хәсәнов, Ә.Еники, Р.Мингалим, Йолдыз, Ф.Сафин, М.Фәйзуллина, Р.Газизов, С.Урайский, Л.Лерон, М.Галиев,М.Шабаев, Э.Шәрифуллина, Г.Мөхәммәтшин,Р.Вәлиева, Р.Корбанәсәрләре.<br>Әсәрләрне анализлый белү, рәссамнарның матурлыкны буяулар белән бирү үзенчәлекәрен белү,картиналардагы матурлыкны күрә белү, табигатьнең матурлыгын күрә белү.<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>Әсәрләрне анализлый белергә, рәссамнарның матурлыкны буяулар белән бирү үзенчәлекәрен белергә,картиналардагы матурлыкны күрә белергә, табигатьнең матурлыгын күрә белергә.<br>**Контроль төрләре:** телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. |
| **8.Кызык һәм көлкеле хәлләр** | **6** | **Бүлекнең төп эчтәлеге:**<br>Л.Лерон,М.Галиев,М.Шабаев,Э.Шәрифуллина,Г.Мөхәммәтшин,Р.Вәлиева,Р.Корбан,Йолдыз әсәрләре.<br>Капма-каршылыкның көлке тудыруын аңлау,үзеңнең кимчелекләреңне әсәрләр аша аңлау, бетерү өстендә эшләү,язучыларның кызыклы хәлләрне җиткерү алымнарына төшенү,юмор хисен аеру, мәзәк өлешне таба белергә өйрәнү,чыга алмаслык кыен хәлләрнең булмавын ачыклау.<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>Капма-каршылыкның көлке тудыруын аңларга,үзеңнең кимчелекләреңне әсәрләр аша аңларга, бетерү өстендә эшләргә,язучыларның кызыклы хәлләрне җиткерү алымнарына төшенергә,юмор хисен аерырга, мәзәк өлешне таба белергә өйрәнергә,чыга алмаслык кыен хәлләрнең булмавын ачыкларга.<br>**Контроль төрләре:** телдән тест.<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. |
| | **68 сәг** | |

**3класс**

| **Бүлекнең исеме** | **сәг.саны** | **Кыскача эчтәлеге** |
|---|---|---|
| **1.Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән** | 15 | Табигатьнең гүзәллеген әдәби һәм сәнгать әсәрләре аша аңлату. Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтеп барырга, күргәннәрең белән уртаклашырга өйрәтү. Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгының шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуына инандыру. Шигырьләрдә чагыштыру, сынландыру, |

| | | |
|---|---|---|
| **уртаклаша быз.** | | эпитет. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).<br>Б.Рәхмәт "Иң күңелле чак", Р.Хисмәтуллин «Июль аланы», Р.Вәлиева "Җәй һәм бала", М.Галиев «Җиләктән кайтканда», М.Мирза "Күздә бермәл", "Күз", "Болыт", Б.Рәхимова «Шук болытлар, батыр җил, якты кояш», М.Гафури "Болын", Н.Дәүли «Бала болыт», Р.Корбан "Күз нигә моңая", Р.Вәлиева "Яңгыр, яу!", "Китмә әле, бераз тор", Йолдыз "Салават күпере", М.Әлимбаев "Салават күпере", Л.Лерон «Яңгырның ял көне», М.Җәлил "Яңгыр", Р.Мингалим «Август каеннары», Ш.Маннур "Көзге урманда", З.Туфайлова «Яфрак ява», Х.Әюпов «Әбиләр чуагы», К.Тәхау "Көзге урман", Р.Әхмәтҗан "Соңгы яфрак", М.Мазунов «Карап торам», Г.Хәсәнов «Кыр казы», Г.Бәширов «Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе», Н.Гыйматдинова «Казлар», Г.Остер «Серне ачты», В.Хәйруллина "Тәрбияче попугай", Н.Сладков "Күзалдавычлар", Р.Әхмәт "Сыкы", Н.Сладков "Кем остарак", Р.Корбан "Мәктәпкә озату бәйрәме", Г.Паушкин "Кыш", Г.Рәхим "Безнең тауда", Н.Әхмәдиев "Чишмәгә суга барам", К.Кәримов "Кышкы мәтрүшкәләр", Н.Гыйматдинова Сарбай".<br>**Эш формалары**: практик-уен, экскурсия, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. |
| **2. Чагыштыр улар серенә төшенәбез.** | 6 | Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.<br>Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау.<br>Әфган халык әкияте: " Иң яхшы дару", "Табышны ничек бүләргә?", "Кабартма"; Уйгур халык әкияте: "Тылсымлы китмән"; Инглиз халык әкияте: "Көрән төстәге пингвин баласы"; Монгол халык әкияте: "Әтәч таңда нигә кычкыра?"; Манси халык әкияте: "Куянның колагы нигә озын?"; Кабарда халык әкияте: "Җәнлекләр патшасы"; Венгр халык әкияте: "Комсызлык бәласы"; Африка негрлары әкияте: "Сырны ничек бүлгәннәр?"; Эстон халык әкияте: "Куянның ирене нигә ярык?"; Эвенк халык әкияте: "Әтәч нигә кычкыра?"; Казакъ халык әкияте: "Юмарт дөя"<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, эчтәлек сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Милли төбәк компоненты:** Төрле халык авыз иҗаты белән танышу |

| | | |
|---|---|---|
| **3.Кешеләр нең хыялларын аңларга тырышабы з.** | 6 | Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы – тыңлаучыга табигый көчләрнең серен , әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү. Уйдырмаларның максаты – тыңлаучыларны дөньяда булмаган,уйлап чыгарылган хәлләр беләншаккатыру.<br>Л.Лерон “Хыял”, Йолдыз “Антенналы бәрәңге”, Л.Лерон “Мәче малае Шукбай”, “Шукбай балык тота”, “Хат”, Р.Фәйзуллин “Тугайда”,<br>А.Гыйләҗев “Суык”, А.Аланазаров “Дустымны эзлим”<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу |
| **Ярату турында** | 9 | Ярату” төшенчәсенең мәгънәсен әдәби әсәрләрдәге вакыйга һәм образлар язмышы аша аңлату: гаиләне хөрмәтләү, гаилә әгъзаларына, туган җиргә карата ярату хисләре, кече туганнарыбызга мәхәббәт. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану.<br>Р.Вәлиев “Барысын да яратам”. Ш.Маннур “Яратам”, Р. Вәлиев “Чыпчык”, С.Урайский “Туган ил”, А. Гыймадиев “Шәмси маҗаралары”В.Нуриев “Кем катырак суга?”. “Музей йорты”на сәяхәт. Б.Кустодиев “Идел. Салават күпере”, Р.Вәлиева “Яңгыр белән Кояш”, Г.Сабитов “Тәүге шатлык”. Ә.Баянов “Тургай”, Н.Гыйматдинова “Болын патшасы”. “Музей йорты”на сәяхәт. Ф.Халиков “Гаилә портреты”, А.Әхмәтгалиева “Безнең чишмә”. “Музей йорты”на сәяхәт. Ф.Әминов “Су буе”,Г. Бәширов “Беренче кар”. Н. Сладков “Кышкы җәй”,М. Мазунов “Яңа карлар ява”. И.Солтан “Кар ник шыгырдый?” Ф.Зыятдинов “Муллык билгесе, Р.Миңнуллин “Кар бәйрәме”. “Музей йорты”на сәяхәт. “Тылсымлы кыш”..**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу |
| **Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз.** | 7 | Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж.Лафонтен, И.Крылов, татар мәсәлчеләре К.Насыйри, Г.Тукай,М.Гафури, Г.Шамуков, Ә.Исхак һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнү. Төрле халык мәкальләре . Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану. Мәсәл һәм әкиятне чагыштыру. Мәсәлләрнең хайваннар турындагы әкиятләрдән килеп чыгуы. Мәсәлләрнең төп асылы, эчтәлеге. Мәсәл моралендә мәкальләр куллану. Мәсәлләрнең тәрбияви роле.<br>Эзоп “Давыл белән Кояш”, Г.Тукай “Җил илә Кояш”, К.Насыйри”Төлке белән әтәч”, Н.Исәнбәт “Ябалак белән Чыпчык”. Татар халык әкияте “Ябалак белән Чыпчык”, Т.Яхин “Карга белән Төлке”, Ф.Яхин “Сыр бәласе”. Г.Шамуков “Карга белән Төлке”, В.Радлов “Карганың хәйләсе”, Л.Толстой “Зирәк Чәүкә”. К. Насыйри “Комсыз эт”,Ә.Исхак “Карт Имән белән яшь егет». М.Гафури «Ике чебен»,Г.Тукай “Төлке һәм йөзем җимеше”, Ә.Исхак “Төлке һәм виноград”, Г.Тукай “Аккош, Чуртан һәм Кысла”, И.Крылов “Аккош, Чуртан һәмКысла”.<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда |

| | | |
|---|---|---|
| | | **Милли төбәк компоненты:** Танылган мәсәлчеләр һәм татар мәсәлчеләре иҗаты белән танышу |
| **Көлке серләрен эзлибез .** | 5 | Шигырьләрдә автор фикерен аерып алу. Шагыйрьнең кимчелекләрдән көлүе. Көлкеле әсәрләрдә көлке китереп чыгарган сәбәпләрне табу.<br>Ш.Галиев “Иншаның файдасы”, “Сүзләре һәм үзләре”. Л.Лерон “Иртән уянасың килмәсә “, Р.Вәлиева “Көчле укучы”, К.Тәңрекулиев “Эшчән” Гельды”, Л.Лерон “Сүз тыңлыйсың килмәсә”, И. Юзеев “Хатасыз ничек язарга?” Р.Миңнуллин “Хаталар өстендә эшләү”, Г.Морат “Үскәч кем булырга?”, Р.Фәйзуллин “Ничек яхшы булырга?” Йолдыз “Ике җаваплы табышмак”, Н.Кәримова “Кое чыпчыгы”, Г.Морат “Тиргиләр”, З.Туфайлова “Трай”, Р.Вәлиев “Минеке”, А.Алиш “Утлы йомырка”<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу |
| **Герой ничек туа?** | 9 | Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Язның тәүге үзенчәлекләрен әсәрләрдән табу.<br>Ф. Яруллин “Тылсымлы ачкыч”, Р. Мингалим “Уйларга кирәк”, Р. Харис “Берсе калсын иде”, Р. Вәлиева “Кышкы ямь”. “Музей йорты”на сәяхәт.<br>Йолдыз “Белмәгәнен белми”, М. Мирза “Язның тәүге көннәре”, Г. Хәсәнов “Май”, Ә. Рәшит “Яшенле яңгыр”, Г. Хәсәнов “Май”.<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, экскурсия, төркемдә һәм парларда<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар  язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу. |
| **Үткәннәр белән хәзергене чагыштыра быз.** | 11 | Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны табу. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).<br>Хикәя геройлары , аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж.<br>Р. Фәйзуллин “Онытма син!” Р. Рәкыйпов “Мин яратам сине, ,Татарстан”Л. Шагыйрьҗан “Сөембикә манарасы”. “Музей йорты”на сәяхәт. М. Мирза “Без бабайсыз үстек”. З.Гомәрова “Батырлар хакында”.В.Хәйруллина “Хозурлык һәм горурлык”Ф. Кәрим “Ант”, “Ватаным өчен”, М.Җәлил “Кичер, илем!” В. Нуруллин “Бүреләр, үгез һәм без”, Г. Ахунов “Канатлар кая илтә?” И. Юзиев “Матурлыкны гына алып кит”, М.Рафиков “Җир куены”, Г.Бәширов “Безнең Татарстан”, Р.Харис ”Игенче җыры”, Йолдыз “Спортчы Шүрәле”, Р.Миңнуллин “Кунакка килегез”<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, экскурсия, төркемдә һәм парларда<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу. |

## 4 нче сыйныфта әдәби уку фәненең эчтәлеге

<table>
<tr><th>Бүлек исеме</th><th>Кыскача эчтәлек</th><th>Сәгать саны</th></tr>
<tr><td>Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез</td><td rowspan="7">Дөнья турында борынгы күзаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы. Тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә. Максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы.) Халык әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.<br>Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар. Аларның килеп чыгышы.Риваять һәм легендаларда бирелгән вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы. Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы. Тотем хайван һәм үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.<br>Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгын шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуын инандыру. Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.<br>Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру,контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре:темп,тавыш көче,тон,сөйләм мелодикасы(тавышны күтәрү,түбәнәйтү).<br>Хикәя жанры турында күзаллау формалаштыруны дәвам итү. Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру ( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.<br>Шагыйрь, язучы, рәссамның биографиясе. а) әсәрдә авторлар кичереше; ә) автор күзәтүләренең чагылыш; б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар. Автор әкиятләренең халык әкиятлре белән охшашлыгы (жанр һәм сюжет). Халык әкиятлрендәге тылсым юлы белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнеңкөче.</td><td>15</td></tr>
<tr><td>Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә авторәкиятләре хисләр дөньясына чакыра.</td><td>7</td></tr>
<tr><td>Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез.</td><td>8</td></tr>
<tr><td>Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз.</td><td>6</td></tr>
<tr><td>Матурлыкның безгә ничек тәэсир иткәнен аңларга тырышабыз.</td><td>11</td></tr>
<tr><td>Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә?</td><td>10</td></tr>
<tr><td>Сәнгать дөньясының үзенәгенә хас үзенчәлекләренaчыклыйбыз.</td><td>3</td></tr>
<tr><td>Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк.Туган ил турында уйланабыз</td><td></td><td>8</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td></td><td>68</td></tr>
</table>